СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2022 г. Агрыз № 16-2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Әгерҗе районы прокуратурасының «Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына 2022 елның 03 мартындагы 02-08-01/3 номерлы протестын исәпкә алып, «Гавами хакимиятне оештыруның һәм аның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләрен җайга салуны камилләштерү турында» Россия Федерациясе Конституциясенә 2020 елның 14 мартындагы 1-ФЗ номерлы төзәтмә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җирле үзидарә буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Советының
10.03.2022 № 16-2
карары белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 29-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр

1. 14 кисәктә:

1.1. 1 өлешнең 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирүче Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы яисә гражданлыгы (подданствосы) туктатылу турында муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирүче Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы яисә гражданлыгы (подданствосы) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча яллаучының вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә;»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле 1 өлеш 9.1 пункт өстәргә:

«9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алган йә яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган очракта, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яисә чит дәүләт территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, язма рәвештә хәбәр итәргә.;».

2. 15 кисәктә:

2.1. 1 өлешнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирүче Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы (подданствосы) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу;»

2.2. 1 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданныц даими яшәү хокукын раслый торган башка документ булу;»;

2.3. 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 7.1 пункты белән тулыландырырга:

«7.1. Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр), акчалата акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклау һәм ачу;»;

3. 19 кисәктә:

3.1. 3 өлешнең 6 пунктында:

«Шәхси (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ» сүзләреннән соң «, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә.;»;

4. 23 кисәктә:

4.1. 1 өлешнең 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.